КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2019 ел, 9 сентябрь

г.Казань

№ 805

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1099 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ нче пункт өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына рекреацияле зоналарны проектлаштырганда, төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, шулай ук аларны паспортлаштырганда бу карар нигезләмәләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларында:

4 бүлектә:

4.1 бүлекчәнең 4.1.14 нче пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.14. Мохит саклау функцияләрен башкаручы җитештерү һәм башка объектларның санитария-саклау зоналары әлеге объектлар урнаша торган территориаль зоналар составына кертелә. Санитария-саклау зоналарыннан файдалануның һәм төзүнең рөхсәт ителә торган режимын гамәлдәге законнар, бу нормативлар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Санитария-саклау зоналарын билгеләү һәм санитария-

яклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 3 мартындагы 222 номерлы карары белән расланган Санитария-саклау зоналарын билгеләү һәм санитария-яклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен файдалану кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр), 2.2.1/2.1.1.1200 нче санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларында китерелгән санитария кагыйдәләре нигезендә, шулай ук санитария-саклау зонасын билгеләү турындагы карар белән күздә тотылган җир кишәрлекләрен файдалану режимы нигезендә кабул итәргә кирәк.»;

4.2 бүлекчәдә:

4.2.38 нче, 4.2.58 нче пунктларда «87 нче таблица һәм бу нормативларга теркәлгән 10 нчы кушымтаның 2 – 6 нчы таблицалары нигезендә» сүзләрен «бу нормативларга теркәлгән 10 нчы кушымтаның 2 – 6 нчы таблицалары нигезендә, шулай ук башка куркынычсызлык таләпләрен үтәп, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив документлар нигезендә янгыннан саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын тәэмин итеп» сүзләренә алыштырырга;

4.2.40 нчы пунктның икенче абзацында «, санитария-эпидемиология күзәтчелеге органнары белән килештереп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2.43 нче пунктның икенче абзацында «һәм санитария-эпидемиология күзәтчелеге органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2.57 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Утар йортына хуҗалык сарае, гараж, мунча, теплица төзү 31-02-2001 нче санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары таләпләрен, бу нормативларга теркәлгән 10 нчы кушымтаның 2 – 6 нчы таблицалары нигезендә янгынга каршы нормаларны үтәп, шулай ук башка куркынычсызлык таләпләрен үтәп, Россия Федерациясе һәм Татар-стан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив документлар ни-гезендә янгыннан саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын тәэмин итеп рөхсәт ителә. Күрше участоклардагы хуҗалык каралтыларын хуҗаларның уртак ризалыгы белән бетереп куярга рөхсәт ителә.»;

4.2.58 нче пунктта «87 нче таблица һәм бу нормативларга теркәлгән 10 нчы кушымтаның 2 – 6 нчы таблицалары нигезендә» сүзләрен «бу нормативларга теркәлгән 10 нчы кушымтаның 2 – 6 нчы таблицалары нигезендә, шулай ук башка куркынычсызлык таләпләрен үтәп, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив документлар нигезендә янгыннан саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын тәэмин итеп» сүзләренә алыштырырга;

4.4 бүлекчәдә:

4.4.10 нчы пунктның беренче абзацында «таләпләре нигезендә» сүзләре алдына «кагыйдәләр» сүзен өстәргә;

4.4.12 нче пунктта «Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең мәҗбүри катнашында» сүзләрен «санитария кагыйдәләре таләпләрен үтәүне исәпкә алып» сүзләренә алыштырырга;

4.4.38 нче пунктта «таләпләре нигезендә» сүзләре алдына «кагыйдәләр» сүзен өстәргә;

4.4.39 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге зоналар территориясендә төзергә рөхсәт ителә торган объектларны урнаштыру санитария-саклау зонасын билгеләү турындагы карар белән күздә тотылган җир кишәрлекләреннән файдалану режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4.4.40 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.40. Санитария-саклау зонасы чикләрендә җир кишәрлекләрен түбәндәге максатларда файдалану рөхсәт ителми:

торак йортлар, белем бирү һәм медицина билгеләнешендәге объектларны, ачык типтагы спорт корылмаларын, балалар ялын һәм аларны савыктыру оешмаларын, рекреацион билгеләнештәге зоналарны һәм гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен урнаштыру;

дару чараларын җитештерү һәм саклау объектларын, сәнәгатьнең азык-төлек тармаклары объектларын, азык-төлек чималының һәм азык-төлек продукциясенең күпләп сату складларын, эчәргә яраклы суны әзерләү һәм саклау өчен суүткәргеч корылмалары комплексларын урнаштыру, азык-төлек продукциясе сыйфатында алга таба файдалану өчен билгеләнгән авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү максатларында җир кишәрлекләреннән файдалану, әгәр дә санитария-саклау зонасы билгеләнгән объектның химик, физик һәм (яки) биологик йогынтысы мондый чаралар, чимал, су һәм продукциянең аларга карата билгеләнгән таләпләр нигезендә сыйфатын һәм куркынычсызлыгын бозуга китерсә.

Санитария-саклау зоналары территориясе рекреация максатларында файдаланылмаска тиеш.

Санитария-саклау зонасы күләме 2.2.1/2.1.1.1200-0 нче санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларының 4.5 нче пунктында курсәтелгән очракларда һәм Кагыйдәләр белән күздә тотылган тәртиптә киметелергә мөмкин.»;

4.7 бүлекчәнең 4.7.26 нчы пунктындагы өченче абзацында татарча текстта «2.2.1/2.1.1.1200-03 нче санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары таләпләре нигезендә» сүзләрен «2.2.1/2.1.1.1200-03 нче санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары, Кагыйдәләрнең 5 нче пункты нигезендә, шулай ук санитария-саклау зонасын билгеләү турындагы карар белән күздә тотылган җир кишәрлекләрен файдалану режимы нигезендә» сүзләренә алыштырырга;

4.5 бүлекчәдә:

4.5.9 нчы пунктта «17 нче таблица» сүзләрен «18 нче таблица» сүзләренә алыштырырга;

4.5.11 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак пунктның планлаштыру структурасында урнашу урынына һәм әһәмиятенә карап, парклар түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

шәһәр паркы – паркны карап тоту һәм масштабы шәһәр яки шәһәр округы халкының ихтыяҗларына туры килә;

торак районы паркы (район паркы) – паркны карап тоту һәм аның масштабы хезмәт күрсәтелә торган райондагы халык ихтыяҗларына туры килә;

авыл торак пункты паркы (авыл паркы) – паркны карап тоту һәм масштабы авыл торак пункты, шәһәр тибындагы поселок халкының ихтыяҗларына туры килә.

Билгеләнешенә һәм функциональ тулыланышына карап, күпфункцияле парклар түбәндәге типларга аерыла:

комплекслы күпфункцияле парк;

махсуслаштырылган күпфункцияле парк (алга таба – махсуслаштырылган парк).

Кагыйдә буларак, махсуслаштырылган парклар бик эре, эре һәм зур шәһәрләрдә оештырыла. Түбәндәге юнәлештәге махсуслаштырылган паркларга аерыла:

спорт паркы – яшел утыртмаларны, сулыкларны, яссы корылмаларны, спорт корылмаларын, шулай ук паркка килүчеләрнең кыска вакытлы ялы өчен корылмаларны бердәм архитектура-планлаштыру структурасына берләштерә торган ландшафт архитектурасы объекты;

балалар паркы – балаларга уйнау, күңел ачу, мәдәни-агарту һәм спорт күнекмәләре белән шөгыльләнү өчен билгеләнүче яшелләндерелгән территориядән гыйбарәт ландшафт архитектурасы объекты;

мемориаль парк – аерым затлар һәм (яки) тарихый вакыйгалар истәлегенә төзелгән һәм урнаштырылган, шәһәр парклары структурасына яраштырылган теләсә нинди сынлы сәнгать, архитектура әсәрләрен һәм техниканы үз эченә алган ландшафт архитектурасы объекты;

күргәзмә паркы – яшел утыртмаларны, сулыкларны, яссы корылмаларны, шулай ук күргәзмә заллары, павильоннар һәм аң белем бирү һәм тамаша билгеләнешендәге корылмалар комплексын бердәм архитектура-планлаштыру структурасына берләштерә торган ландшафт архитектурасы объекты;

этнография паркы – яшел утыртмаларны, сулыкларны, яссы корылмаларны бердәм архитектура-планлаштыру структурасына берләштерә торган һәм табигый ландшафт шартларында үткән вакыт торак, көнкүреш һәм мәдәни корылмаларының уникаль үрнәкләрен күрсәтү өчен билгеләнгән ландшафт архитектурасы объекты;

ботаника паркы, дендропарк – рекреацион эшчәнлекнең фәнни-тикшеренү һәм мәдәни-агарту юнәлешендәге ландшафт архитектурасы объекты, аларның территориясендә үз илебез һәм дөньякүләм флорасының үсемлек ресурсларын өйрәнү, шулай ук биологик фән өлкәсендә белемнәрне тарату буенча мәдәни-агарту эшләре алып барыла;

күңел ачу паркы – рекреацион эшчәнлекнең күңел ачу юнәлешендәге ландшафт архитектурасы объекты, алар территориясендә тамаша чаралары һәм аттракционнар үткәрү өчен ачык мәйданчыклар урнаштырыла;

сәламәтләндерү паркы – сәламәтлек саклау учреждениеләренә килүчеләр һәм аларның пациентлары ял итү һәм йөреп күңел ачу өчен билгеләнгән, яшелләндерелгән территориядән гыйбарәт булган ландшафт архитектурасы объекты.

Әһәмиятенә, урнашу урынына һәм рекреацион йөкләнешенә карап, рекреацион зоналар түбәндәге ярдәмче типларга аерыла:

1 нче ярдәмче тип – кимендә 500 мең халкы булган торак пунктларда рекреацион йөкләнеше күтәренке булган (туристлар агымын исәпкә алып) үзәк

шәһәр күпфункцияле паркы, шулай ук тарихый-мәдәни мирас объектларына караган һәм күп туристлар агымын җәлеп итү урыны булган парклар һәм скверлар;

2 нче ярдәмче тип – кимендә 100 мең халкы булган торак пунктларда яки шәһәр округының административ берәмлекләрендә рекреацион йөкләнеше югары булган шәһәр, район күпфункцияле паркы;

3 нче ярдәмче тип – рекреацион йөкләнеше уртача һәм түбән булган шәһәр, район, авыл күпфункцияле паркы, скверы, бульвары;

4 нче ярдәмче тип – рекреацион йөкләнеше түбән булган шәһәр, район, авыл күпфункцияле паркы, скверы, бульвары;

5 нче ярдәмче тип – урман паркы.

Рекреацион зонаның комплекслы төзекләндерү элементлары бәйләнешенә карап, парклар биш категориягә аерыла. Паркларны һәм скверларны категорияләргә кертү принциплары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карары белән билгеләнгән;

4.5.13 нче пунктта «18 нче таблица» сүзләрен «21 – 28 нче таблицалар» сүзләренә алыштырырга;

4.5.14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.14. Һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеге радиусы түбәндәгеләрне тәшкил итәргә тиеш:

шәһәр парклары өчен – җәмәгать транспортында иң күбе 20 минут;

торак районнар (микрорайоннар) парклары өчен – иң күбе 15 минут, яки һәркем өчен җәяү файдалана алу мөмкинлеге 1 200 метр (42.13330.2011 нче кагыйдәләр җыентыгының 9.15 нче пункты).

18 нче таблица

Яңа рекреацион объектның һәм рекреацион зоналарның
гамәлдәге территорияләрен һәркем өчен файдалана алу мөмкинлеген билгеләү

| Рекреацион объект тибы | Иң чик рекреацион йөкләнеш – бер тапкыр паркка килүчеләр саны, бер гектарга кеше | Һәркем файдалана алу мөмкинлеге радиусы |
|---|---|---|
| Урманнар: | | - |
| караңгы ылыслы | 1-3 тән артык түгел | |
| якты ылыслы | 3 тән артык түгел | |
| киң яфраклы катнаш | 8 дән артык түгел | |
| урман болыннары | 20 дән артык түгел | |
| Урман парклары | 10 нан артык түгел | Транспорт белән файдалана алу мөмкинлеге 15 – 20 минут |

| Рекреацион объект тибы | Иң чик рекреацион йөкләнеш – бер тапкыр паркка килүчеләр саны, бер гектарга кеше | Һәркем файдалана алу мөмкинлеге радиусы |
|---|---|---|
| Болын парклары | 10 нан артык түгел | Транспорт белән файдалана алу мөмкинлеге 15 – 20 минут |
| Су парклары | 10 нан артык түгел | Транспорт белән файдалана алу мөмкинлеге 15 – 20 минут |
| Шәһәр парклары | 100 дән артык түгел | 1 200 – 1 500 метр |
| Ял итү зоналары парклары | 70 тән артык түгел | Транспорт белән файдалана алу мөмкинлеге 15 – 20 минут |
| Бакчалар | 100 дән артык түгел | 400 – 600 метр |
| Скверлар | 100 һәм аннан күбрәк | 300 – 400 метр |
| Бульварлар | 100 һәм аннан күбрәк | 300 – 400 метр |

Көтелә торган рекреацион йөкләнешне билгеләгәндә рекреация территориясендә бер үк вакытта паркка килүчеләр санын рекреация объектыннан (махсуслаштырылган балалар паркларыннан, урман паркларыннан тыш) һәркем файдалана алу мөмкинлеге радиусында яшәүче халык саныннан 10 – 15 процентка тигез итеп (1 көнгә рекреацияләрдә булу коэффициенты) кабул итәргә тәкъдим ителә. Рекреацион йөкләнеш түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$R = \frac{N}{S},$$

монда:

R – рекреацион йөкләнеш, бер гектарга кеше;

N – рекреация территориясендә бер үк вакытта булган кешеләр саны, кеше;

S – рекреацион зона мәйданы, гектар.

Бер рекреация объекты территориясендә төрле дәрәҗәләрдәге рекреацион йөкләнешле зоналарга бүленергә мөмкин.

Балалар паркларының көтелә торган рекреацион йөкләнеше рекреация объектыннан файдалана алу мөмкинлеге радиусында яшәүче балаларның 30 процентыннан (шулардан: 10 проценты – кече яшьтәге, 10 проценты – урта яшьтәге, 5 проценты – өлкән яшьтәге мәктәп укучылары, 5 проценты – мәктәпкәчә яшьтәге балалар) яки шәһәр балаларының барысыннан 7 процент (шулардан 2 проценты – кече яшьтәге, 3 проценты – урта яшьтәге, 1 проценты – өлкән яшьтәге мәктәп укучылары, 1 проценты – мәктәпкәчә яшьтәге балалар) исәбеннән чыгып билгеләнә.

Факттагы рекреацион йөкләнеш үлчәүләр белән билгеләнә.

Рекреацион зонаның факттагы рекреацион йөкләнеше көтелә торган күләмнән зур якка тайпылган очракта, рекреацион зонаның табигый мохитенә тискәре йогынты ясауны киметү буенча өстәмә чаралар күрергә кирәк.

Күтәренке рекреацион йөкләнешкә түбәндәге күрсәткеч туры килә:

парклар өчен – 1 гектарга 121 кешедән алып һәм аннан күбрәк;

урман парклары өчен – 1 гектарга 31 кешедән алып һәм аннан күбрәк;

скверлар, бульварлар, бакчалар өчен – бер гектарга 201 кешедән алып һәм аннан күбрәк.

Югары рекреацион йөкләнешкә түбәндәге күрсәткеч туры килә:

парклар өчен – 1 гектарга 101 – 120 кеше;

урман парклары өчен – 1 гектарга 11 – 30 кеше;

скверлар, бульварлар, бакчалар өчен – 1 гектарга 101 – 200 кеше.

Уртача рекреацион йөкләнешкә түбәндәге күрсәткеч туры килә:

парклар өчен – 1 гектарга 71 – 100 кеше;

урман парклары өчен – 1 гектарга 6 – 10 кеше;

скверлар, бульварлар, бакчалар өчен – 1 гектарга 61 – 100 кеше.

Түбән рекреацион йөкләнешкә түбәндәге күрсәткеч туры килә:

парклар өчен – 1 гектарга иң күбе 70 кеше;

урман парклары өчен – 1 гектарга иң күбе 5 кеше;

скверлар, бульварлар, бакчалар өчен – 1 гектарга иң күбе 60 кеше.

Рекреацион территорияләрнең табигый потенциалын саклап калу максатларында, табигый рекреацион ресурсларны саклау, ярдәм күрсәтү, торгызу буенча шартлар булдыру һәм аларның үтәлеше буенча мониторинг режимында даими тикшерүне гамәлгә ашыру зарур.

Тискәре йогынтыны киметү чаралары – алар юл-сукмак челтәренә төрле материаллар түшәү, юл-сукмак челтәренең киңлеген аны файдалану ешлыгына карап җайга салу, аеруча кыйммәтле үсемлек берләшмәләрен бордюрлар, декоратив коймалар, тере киртәләр белән әйләндереп алу, парк үсемлекләрен даими карау һәм аларны яңадан торгызу буенча чаралар үткәрү, халык ял итү өчен мәйданчыклар оештыру. Рекреацион йөкләнешләренә бәйле рәвештә, паркларны, скверларны, бульварларны, бакчаларны төзекләндерүгә карата таләпләр 19 нчы таблицада китерелә. Урман паркларын төзекләндерүгә карата таләпләр 20 нче таблицада китерелә.

19 нчы таблица

Паркларны, скверларны, бульварларны,
бакчаларны төзекләндерүгә карата таләпләр

| Ял итүчеләр тыгызлыгы, бер гектарга кеше | Төзекләндерү буенча чаралар |
|---|---|
| Кимендә 50 | Юл-сукмак челтәре өслекләре – йомшак, катнаш яки каты (табигый материаллар яки тротуар плитәсе),<br>мәйданчыклар өслеге – газон яки йомшак,<br>яшел утыртмаларның торышына мониторинг һәм рекреацион зонаны карап тоту буенча эшләр үткәрү |
| 50 | Юл челтәре өслекләре – катнаш яки каты (табигый материаллар (агач, таш) яки тротуар плитәсе),<br>мәйданчыклар өслеге – йомшак яки катнаш, |

| Ял итүчеләр тыгызлыгы, бер гектарга кеше | Төзекләндерү буенча чаралар |
|---|---|
| | юл челтәрен бордюр ташы яки декоратив киртә белән каймалау,<br>яшел утыртмаларның торышына мониторинг һәм рекреацион зонаны карап тоту буенча эшләр үткәрү |
| 80 | Юл челтәре өслекләре – катнаш яки каты (табигый материаллар (агач, таш) яки тротуар плитәсе),<br>мәйданчыклар өслеге – катнаш,<br>юлларны бордюр ташы яки декоратив киртә белән каймалау,<br>түшәлгән юл челтәре буенча катгый хәрәкәт итү,<br>яшел утыртмаларның торышына мониторинг һәм рекреацион зонаны карап тоту буенча эшләр үткәрү |
| 100 | Юл челтәре өслекләре – күбесенчә каты (табигый материаллар (агач, таш) яки тротуар плитәсе), аеруча йөкләнешле юлларны асфальтлау,<br>мәйданчыклар өслеге – каты өслекләрне кулланып катнаш,<br>юлларны бордюр ташы яки декоратив киртә белән каймалау,<br>түшәлгән юл челтәре буенча катгый хәрәкәт итү,<br>тере киртәләр һәм коймалар белән яшелләндерелгән территорияләрне саклау,<br>буфер һәм туфрак саклау утыртмаларын куллану,<br>тапталуга чыдам газонлы үләннәр куллану,<br>яшел утыртмаларның торышына мониторинг һәм рекреацион зонаны карап тоту буенча эшләр үткәрү |
| 130 һәм аннан күбрәк | Юл челтәрен асфальтлау,<br>мәйданчыклар өслеге – каты өслекләрне кулланып катнаш,<br>юлларны бордюр ташы яки декоратив киртә белән каймалау,<br>түшәлгән юл челтәре буенча катгый хәрәкәт итү,<br>бордюрлар, тере киртәләр һәм коймалар белән яшелләндерелгән территорияләрне саклау,<br>бөтен вегетатив чор дәвамында парк үсемлекләрен даими торгызу өчен карау,<br>буфер һәм туфрак саклау утыртмаларын куллану,<br>тапталуга чыдам газонлы үләннәр куллану,<br>паркның яшел утыртмалары торышын мониторинглау,<br>яшел утыртмаларның торышына мониторинг һәм рекреацион зонаны карап тоту буенча эшләр үткәрү |

20 нче таблица

## Урман паркларын төзекләндерүгә карата таләпләр

| Рекреацион йөкләнеш, бер гектарга кеше | Төзекләндерү буенча чаралар |
|---|---|
| 1 – 5 | Ландшафт кагылгысыз, табигый хәлдә кала, су агымнары һәм чокырлар аша чыгу урыннары оештырыла, тыныч ял итү һәм орнитологик күзәтүләр өчен урыннар җиһазландырыла, ял итү өчен эскәмияләр куела |
| 5 – 10 | Табигый үсемлекләр саклана, табигый мохиткә явым-төшемнән ышык урыннар, япмалар, ял итү өчен эскәмияләр, күперләр һәм су агымнары аша чыгу урыннары булдырыла. Грунт һәм яхшыртылган грунт юллары |

| Рекреацион йөкләнеш, бер гектарга кеше | Төзекләндерү буенча чаралар |
|---|---|
| | иң күбе 5 процент, асфальт хуҗалык мәйданчыкларында (чүп җыю урыннары) гына |
| 10 – 20 | Табигать мохите җил һәм давыл аударганнарны чистарту юлы белән төзекләндерелә һәм үзгәртелә. Мәйданчыклар белән юл-сукмак челтәре зона мәйданының 10 процентына кадәр тәшкил итә. Мәйданчыкларда япмалар, туристлар өчен приютлар, учаклар, чүп җыю урыннары, ясалма яки табигый эчәргә яраклы су чыганаклары, бәдрәфләр урнаштырыла. Бәдрәфләрдән җәяүлеләр файдалана алу мөмкинлеге зонасы – 2 километр. Юлларның өслеге яхшыртылган грунт. Юллар һәм сукмаклар (рекреацион йөкләнешкә карап) грунт яки су үткәрүчәнлек үзенчәлекләре белән түшәлгән табигый материаллар (агач, таш). Ял итү өчен эскәмияләр куела |
| 20 – 50 | Табигать мохите җил һәм давыл аударганнарны чистарту юлы белән төзекләндерелә һәм үзгәртелә. Мәйданчыклар белән юл-сукмак челтәре зона мәйданының 15 процентына кадәр тәшкил итә. Мәйданчыкларда һәм аланнарда япмалар, учаклар һәм мангаллар, чүп җыю урыннары, эскәмияләр, беседкалар, ясалма яки табигый эчәргә яраклы су чыганаклары, бәдрәфләр, пикниклар һәм ял итү өчен җиһаз урнаштырыла. Парк җиһазы һәм корылмалары (ышыклану урыннары, чатырлар), ландшафт үзенчәлекләрен исәпкә алып, табигый материаллардан эшләнә. Бәдрәфләрнең һәм эчәргә яраклы су чыганакларының җәяүлеләр файдалана алу мөмкинлеге зонасы – 1,5 километр. Юллар өслеге – яхшыртылган грунт. Рекреацион йөкләнешенә карап, юллар һәм сукмаклар – грунт яки су үткәрүчәнлек үзенчәлекләре белән түшәлгән табигый материаллар (агач, таш) |
| 50 һәм аннан күбрәк | Парклар шартлары. Түбәндәгеләрне үз эченә ала торган парк тибындагы төзекләндерү: җәяү йөрү зонасы (40 – 75 процент), спорт-сәламәтләндерү зонасы (10 – 20 процент), массакүләм һәм мәдәни-агарту чаралары зоналары (3 – 8 процент), балалар өчен ял итү зонасы (5 – 10 процент), хуҗалык зонасы (2 – 5 процент)»; |

4.5.15 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.15. Күпфункцияле паркларны функциональ-планлаштыру буенча оештыру һәм парк объектлары халыкның төрле ял итү төрләрендәге ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итәргә тиеш.

Парклар түбәндәге зоналарны үз эченә ала:

мәдәни-агарту чаралары зонасы;

массакүләм чаралар зонасы;

физкультура-савыктыру чаралары зонасы;

балалар өчен ял итү зонасы;

җәяү йөрү зонасы, төрле дәрәҗәдәге йөкләнеш белән сәламәтләндерү өчен җәяү йөрү зонасы;

административ, хуҗалык зоналары.

Парк территориясендә паркка килүчеләргә хезмәт күрсәтү һәм паркны эксплуатацияләү өчен биналар төзергә рөхсәт ителә. Төзелеш мәйданы парк территориясенең 5 процентыннан артмаска тиеш.

Паркның функциональ зоналарының тәкъдим ителгән бәйләнеше 21 нче таблицада китерелә.

21 нче таблица

Парк территориясен функциональ оештыру

| Паркның файдалану төрләре буенча функциональ зоналары | Парк зоналарының җир участоклары күләмнәре | |
|---|---|---|
| | паркның гомуми мәйданыннан процент | кв.метр/кеше |
| Мәдәни-агарту чаралары зонасы | 3 – 8 | 10 – 20 |
| Массакүләм чаралар зонасы (тамаша, аттракционнар һәм башкалар) | 5 – 17 | 30 – 40 |
| Физкультура-сәламәтләндерү чаралары зонасы | 10 – 20 | 75 – 100 |
| Балалар өчен ял итү зонасы | 5 – 10 | 80 – 170 |
| Җәяү йөрү зонасы | 40 – 75 | 200 |
| Хуҗалык зонасы | 2 – 5 | – |

Һәр зона, әлеге климат зонасы өчен хас булган үсемлек төрләрен кулланып, бизәлергә мөмкин:

җәяү йөрү зонасы өчен – агач-куак утыртмалары белән интенсив яшелләндерү: ешлыклар, чәчәк түтәлләре, үсемлекләр галереяләре, тере киртәләр һәм башкалар;

физкультура-сәламәтләндерү чаралары зонасы өчен – ачык киңлекләрдә махсус спорт газоннары оештыру;

массакүләм чаралар һәм балалар өчен ял итү зоналары югары декоративлык таләп итә: күпьеллык үсемлекләрнең декоратив формалары, чәчәк түтәлләренең төрле төрләре, тере киртәләр.

Һәр зона паркның планлаштыру структурасында билгеле бер урын алып торырга тиеш. Килүчеләр иң күп булган зоналар паркка керү юлында булырга һәм керү комплекслары – массакүләм чаралар, ял итү объектлары зоналары белән кыска вакыт аралыгында булырга тиеш. Уеннар, күңел ачулар өчен мәйданчыкларны, уен һәм спорт инвентарен прокатка бирү пунктларын төп җәяү йөрү юллары янында урнаштыру максатка ярашлы була. Спорт мәйданчыклары паркның бер урынында гына да (парк мәйданы 20 гектарга кадәр булганда), берничә урынында да (парк мәйданы 20 гектардан артыграк булганда) урнашырга мөмкин. Тыныч ял итү зонасын кешеләр иң аз йөри торган урыннарда оештырырга кирәк.

Керү зоналарында каравылчылар пунктын, яктырткыч белән (кирәк булганда) мәгълүмат стендлары, кассалар, уен һәм спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары, киосклар, туклану объектлары, бәдрәфләрне урнаштырырга тәкъдим ителә.

Тамашачылар урыннары белән спорт мәйданчыклары килүчеләрне эвакуацияләү мөмкинлеген исәпкә алып урнаштырылырга тиеш.

Күпфункцияле парк территориясендә яки аның янындагы территориядә килүчеләрнең транспорт чараларын – автомобильләрне куеп тору урыннарын урнаштыру өчен махсус ачык мәйдан бүлеп бирергә мөмкин.

Паркка килүчеләр өчен автомобильләрне куеп тору урыннары паркның читендә, янындагы территорияләрдә урнаштырылырга мөмкин. Парковка урыннарына ихтыяҗ исәпләп билгеләнә һәм паркка берьюлы 100 килүчегә кимендә 5 – 7 машина урыны тәшкил итә. Автомобильләрне куеп тору урыннарының җир кишәрлекләренең күләмнәрен бер урынга: җиңел автомобильләр өчен – 25 кв.метр, автобуслар өчен – 40 кв.метр, велосипедлар өчен – 0,9 кв.метр кабул итәргә кирәк.

Кышкы чорда паркларны яхшырак файдалану өчен ел әйләнәсе эшләүче учреждениеләрне (мәдәни-агарту, тамаша, прокат һәм туклану пунктлары) төп керүләр юллары янында урнаштырырга кирәк.

Спорт юнәлешендәге махсуслаштырылган паркларда (спорт паркларында) беренче урын физкультура һәм спортка, физик үстерү һәм сәламәтләндерү өчен шәһәр халкының актив ялына бирелә. Спорт парклары 20 гектардан 50 гектарга кадәр мәйданны били.

Спорт парклары түбәндәгеләргә бүленә:

спортчыларның төрле спорт төрләре буенча ярышлар һәм күнегүләр өчен билгеләнгән махсуслаштырылган;

актив ял һәм спорт тибындагы уеннар өчен файдаланыла торган комплекслы (физкультура-савыктыру).

Территорияне функциональ зоналаштыру түбәндәгечә билгеләнә:

төгәл хәрәкәт графигы белән; спортчыларны һәм паркта ял итүче тамашачыларны бүлеп;

актив ял итү өчен демонстрацион, укыту-күнекмәләр ясау корылмаларына һәм актив ял итү өчен корылмаларга килүчеләр белән тулыландырып һәм аларны эвакуацияләп;

спортчыларның һәм паркка килүчеләрнең физик, психик көчләрен торгызу өчен рекреацион территорияләргә бүлеп.

Территорияне планлаштыру ягыннан оештыру, кагыйдә буларак, ачык һәм ябык киңлекләрнең контрастында булдырыла.

Спорт парклары халыкның күпләп килүенә карап исәпләп чыгарыла. Спорт паркының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары 22 нче таблицада китерелә.

22 нче таблица

Спорт паркының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Җәяү йөрү зонасы һәм тыныч ял итү зонасы* | 30 га кадәр |
| Физкультура-сәламәтләндерү чаралары зонасы | 60 ка кадәр |
| Массакүләм чаралар зонасы (тамашалар, аттракционнар һәм башкалар) | 5 – 7 |

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Хуҗалык зонасы | 2 – 5 |
| ** Җәяү йөрү һәм тыныч ял итү өчен функциональ зона составында балалар өчен ял итү зонасының мәйданы исәпкә алынган.* | |

Физкультура-сәламәтләндерү чаралары зонасы билгеле бер функциональ юнәлешкә ия булырга яки секторларга бүленергә мөмкин. Катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү өчен су-мотор, ату, автомобиль, ат спорты һ.б. секторларын изоляцияләүне күздә тотарга кирәк.

Территорияне яшелләндергәндә ачык спорт корылмаларын җилдән һәм тавыштан саклауга карата таләпләрне игътибарга алырга кирәк. Мәйданчыкларның уен киңлегенә яшел утыртмалар белән күләгәләр ясарга кирәкми. Спорт комплексы (яки аерым мәйданчыклар) чиге буйлап, саклагыч яшел утыртмалар полосасын күздә тотарга кирәк.

Спорт мәйданчыклары тирәсендәге кишәрлекләрне яшелләндергәндә яфракларның төсе һәм фактурасы, чәчәк атуның характеры игътибарга алына. Яктырак төстәге яфраклы үсемлекләр, шулай ук чәчәк ата торган куаклар утыртырга киңәш ителми, чөнки алар куакның көпшәк структурасы, ябалдашларның ажурлыгы, якты тональлеге аркасында уеннар өчен уңайсыз фон тудыра. Уен мәйданчыкларын һәм ачык йөзү бассейннарын чүпләндерә торган үсемлекләрне (энәле, орлыклы, чәчәкләре таҗлы), җил сындыруга бирешүчән (көмешсыман өрәңге һ.б.), кырау сугучан (экзотлар), шулай ук яфраклары һәм җимешләре иртә коела торган агачлар, үсемлекләрнең интродуцирован төрләре ассортименттан төшереп калдырыла.

Балалар юнәлешендәге махсуслаштырылган паркларның (балалар паркларының) күләмнәрен (исәп-хисап нормалары 42.13330.2011 нче кагыйдәләр җыентыгы белән расланган мәйданчыкларны һәм спорт корылмаларын кертеп) 1 кешегә 0,5 кв.метр исәбеннән чыгып кабул итәргә рөхсәт ителә,

Балалар паркы территориясен функциональ-планлаштыру буенча оештыру, тәрбия бирү һәм сәламәтләндерү эшләре бүлекләреннән чыгып, түбәндәге зоналарга бүленеп билгеләнә (23 нче таблица).

23 нче таблица

Балалар паркының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Җәяү йөрү зонасы һәм тыныч ял итү зонасы | 40 – 75 |
| Балалар өчен ял итү зонасы | 8 – 10 |
| Физкультура-сәламәтләндерү чаралары зонасы | 10 – 15 |
| Мәдәни-тәрбия бирү зонасы, массакүләм чаралар зонасы (тамашалар, аттракционнар һәм башкалар) | 10 – 20 |
| Хуҗалык зонасы | 2 – 5 |

Мәдәни-тәрбия бирү зонасы мөстәкыйль территориядә урнашырга яки объектлар буенча бүленергә мөмкин.

Физкультура-савыктыру чаралары зонасы (мәйданы буенча зур булган парклар өчен) төрле спорт җайланмалары белән җиһазландырыла. Спорт зонасында шулай ук шөгыльләнү өчен павильоннар, гардероблар, душ бүлмәләре, велосипедларны, чаңгыларны һәм тимераякларны прокатка алу пунктлары, медицина пунктлары һәм тренерлар өчен бүлмәләр урнаштырыла.

Массакүләм чаралар зонасы барлык яшь төркемнәренә бергәләп файдалану өчен төп комплексны һәм балаларның һәр яшь төркеме өчен бүлеп бирелгән объектларны үз эченә ала. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм кече мәктәп укучылары өчен уен комплексларын төп керү юлыннан ерак булмаган аерым участокларда урнаштырырга тәкъдим ителә.

Балалар өчен уен җиһазлары вандалларга каршы, якты, тәэсирле һәм нык булырга, эстетик сыйфатларга ия булырга тиеш.

Мәйданчыкларның күләмнәре, юллар габаритлары зона территориясенә рекреацион йөкләнеш нигезендә исәпләнгән булырга тиеш. Мәйданчыклар, гамәлдәге таләпләр нигезендә, дөрес ориентлаштырылган, җилдән һәм җәй көне артык кояш нурланышыннан саклау чарасы белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Махсуслаштырылган күргәзмә парклары аерымланган территориядә һәм күпфункцияле парклар территориясендә күргәзмә секторы буларак урнаштырылырга мөмкин. Күргәзмә паркын шәһәр планында һәм аның территориясенең архитектура-планлаштыру өлешендә урнаштыру күргәзмәләр үткәрүнең характерына һәм дәвамлылыгына бәйле. Күргәзмә паркы стационар, даими гамәлдә һәм даими булмаган, вакыйгаларга, истәлекле даталарга багышланган булырга мөмкин.

Парк күләме экспозициянең билгеләнеше һәм характеры белән билгеләнә һәм уртача 5 – 15 гектардан 50 гектарга кадәр тәшкил итә. Күргәзмә паркларын гомумшәһәр үзәгендә, үзәк шәһәр районында, планлаштыру районы үзәгендә, даими күргәзмә парклары өчен рекреацион территорияләрдә (шәһәр «бусагасы»нда) урнаштырыла.

Күргәзмә бакча-парк объектлары түбәндәгеләргә бүленә:

сәүдә (коммерция);

аң-белем бирү (фәнни-техник, сәнгать, авыл хуҗалыгы);

билгеле бер вакыт аралыгы өчен оештырыла торган;

юбилейларга яки истәлекле даталарга багышланган;

даими эшли торган (стационар);

универсаль, махсуслаштырылган, тематик.

Экспозициянең билгеләнеше, анда катнашучылар составы буенча күргәзмә парклар бөтендөнья, халыкара, милли, республика, төбәк, өлкә, шәһәр һәм районнарга бүленә. Күргәзмә паркларның функцияләре фән һәм техника, сәнәгать, авыл һәм урман хуҗалыклары, мәдәният һәм бакча-парк сәнгатенең казанышлары белән танышудан гыйбарәт. Ландшафтны проектлаштырганда территорияне функциональ оештыруга һәм барлык ландшафт композициясе үзәген билгеләүгә зур әһәмият бирелә. Күргәзмә паркның функциональ зоналары 24 нче таблицада китерелә.

24 нче таблица

Күргәзмә паркының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Экспозиция зонасы | 60 – 40 |
| Клуб, музей зоналары, фәнни-методик эш зонасы, ял итү зонасы | 10 – 20 |
| Административ зона | 2 – 10 |
| Хезмәт күрсәтү зонасы | 15 – 30 |
| Хуҗалык зонасы | 2 – 5 |

Күргәзмә паркын зоналарга бүлгәндә үзәк участоклар экспозиция өчен бирелә, ә периферия участоклары ял итү, балалар уеннары һәм аттракционнар өчен кулланыла. Мондый объектлар өчен 100 гектардан 600 гектарга кадәр мәйданлы территорияләрне күздә тота. Кайбер очракларда, табигать шартлары күргәзмә комплексларының композицион нигезе булып тора.

Махсус ботаника парклары, дендропарк – фәнни-тикшеренү учреждениесе булган һәм авыл һәм урман хуҗалыкларын баету, сәнәгатьнең парфюмерия, дару һәм химия тармакларын чимал белән тәэмин итү өчен үз илебезнең һәм дөнья флорасы ресурсларын өйрәнү белән шөгыльләнүче махсуслаштырылган парк.

Территория зурлыгына карап, ботаника бакчалары түбәндәге төркемнәргә бүленә: кечкенә – 30 гектарга кадәр, уртача – 30 – 100 гектар, эре – 100 – 300 гектар, иң эреләре – 300 гектардан артыграк.

Ботаника паркларының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары нисбәте 25 нче таблицада китерелә.

25 нче таблица

Ботаника паркының тәкъдим ителә торган функциональ зоналары

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Экспозиция, җәяү йөрү зоналары, күңел ачу зонасы | 40 – 60 |
| Административ зона | 20 – 30 |
| Хуьалык зонасы | 2 – 5 |

Махсуслаштырылган мемориаль парклар – һәйкәлләр, истәлекле билгеләрне кую, массакүләм һәм индивидуаль каберлекләрне оештыру өчен билгеләнгән ландшафт архитектурасы объектлары буларак махсуслаштырылган паркларның аерым төре.

Мемориаль парклар үз әһәмияте һәм масштабы буенча түбәндәгеләргә бүленә:

монументаль зур ансамбльләр (шул исәптән мемориаль зиратлар);

истәлекле билгеләр белән мемориаль территорияләр;

киң урбанистик характердагы истәлекле комплекслар;

мемориаль камера ансамбльләре;

гражданнар зиратлары, хәтер парклары.

Мемориаль объектларны урнаштыру принцибы буенча мемориаль парклар тарихый-документаль, шәһәр төзелеше һәм берләштерелгән типка бүленә.

Мемориаль паркның функциональ зоналары нисбәте 26 нчы таблицада китерелә.

26 нчы таблица

Мемориаль паркның тәкъдим ителә торган функциональ зоналары

| Паркның функциональ зонасы исеме | Зона мәйданы, процент |
|---|---|
| Мемориаль зона | 20 – 55 |
| Административ, хуҗалык зоналары, хезмәт күрсәтү зонасы | 10 – 25 |

Мемориаль зона түбәндәгеләрне үз эченә ала:

экспозицияләр зонасы (мактаулы җирләү ансамбльләре, чын мемориаль объектлар, истәлекле агачлыклар, калкулыклар, павильоннар, музейлар, кече архитектура формалары, бердәмлек җырлары һәм сәяси җырлар фестивальләре һәм митинглар өчен мәйдан яки болын);

веноклар салу һәм антлар кабул итү өчен мәйданчыклар;

мәгълүмати хәбәрләр өчен мәйданчыклар;

җәяү йөрү һәм ял итү өчен территорияләр.

Экспозиция зонасының күләме-киңлеге буенча чишелеше мемориаль объектның үзенчәлеген билгели. Хәрәкәт маршрутлары музей маршрутлары белән охшаш. Аларның схемалары барлык төр булуларны исәпкә алырга тиеш – экскурсия, ялгыз, кызыксынулар буенча, таныштыру. Алар ябык һәм линияле ирекле принциплар буенча проектлаштырылырга мөмкин. Экспозиция зонасының планлаштыру буенча оештыру, күләм-киңлек композициясе элементлары составына һәм аларны кабул итү үзенчәлекләренә туры китереп, маршрут божраларын оештыруны күз алдында тота. Төп элементлар керү зонасына якынрак урнаша һәм ландшафтта өстенлек итәргә тиеш. Калган элементларны, кабул итү үзенчәлекләрен исәпкә алып, әлеге программа буенча урнаштырырга кирәк. Массакүләм чаралар (ритуаль, әдәби укулар, митинглар) өчен кулланыла торган элементлар халыкның зур массалары булуга шартлар тудыру өчен бер-берсенә карата тупланып урнаштырыла. Функциональ зоналарның чигендә һәм төп экспозициядән читтә төп зонаның характерын бозмый торган, иркенрәк күләм-киңлек һәм архитектура корылмалары булырга мөмкин. Керү зонасы килүче белән эшләү өчен үсеш алган күләм-планлаштыру чишелешен алырга тиеш. Монда зур үлчәмле элементларны – символларны урнаштыру максатка ярашлы була. Фәнни-методик, кинолекцион, китапханә эше өчен шартлар тәэмин ителә.

Махсуслаштырылган этнографик парклар – бу халык иҗаты, көнкүреш һәм архитектура музей парклары. Алар территориясендә халык иҗаты фестивальләре, фольклор ансамбльләре чыгышы, халык бәйрәмнәре, күңел ачулар һәм ярминкәләр

үткәрелергә мөмкин. Ландшафт архитектурасының мондый махсус объектлары мәдәни-танып белү парклары төркеменә керә.

